**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ**
**ЛЬЯШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТӘТЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЛЬЯШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

422375 с. Льяшево, ул. Пролетарская, 22А

422375 Льяш авылы, Пролетар урамы, 22А

тел., факс (84373) 55-8-26, e-mail: Lsv.tet@tatar.ru
ОГРН 1021606556971, ИНН/КПП 1638001624/163801001

---

# КАРАР

**12 марта 2020 года** **№ 54-1**

**«Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы «Льяш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»гы Тәтеш муниципаль районы Льяш авыл җирлеге Советы карары проекты хакында**

Тәтеш муниципаль районы Льяш авыл җирлеге Советының 2013 елның 24 гыйнварындагы 27-3 номерлы карары нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы «Льяш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы «Льяш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 86-88 статьялары нигезендә, Россия Федерациясенең гамәлдәге законына туры китерү максатыннан, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Льяш авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Льяш авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы «Льяш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»гы карары проектын (алга таба – карар проекты) 1 нче кушымта нигезендә беренче укылышта кабул итәргә.

2. 2 нче кушымта нигезендә карар проекты буенча комиссия составын расларга.

3. 3 нче кушымта нигезендә карар проекты турында фикер алышуда гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен расларга.

4. 4 нче кушымта нигезендә карар проекты турында фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибен расларга.

5. Обнародовать на специальных информационных стендах, расположенных на территории населенных пунктов: Республика Татарстан, Тетюшский район, с. Льяшево, ул. Советская, 21а; с. Большое Бисярино, ул. Заовражная, д. 33; д. Ямбухтино, ул. 60 лет Октября, д. 24а:

- проект решения;

Татарстан Республикасы, Тәтеш районы, Льяш авылы, Совет урамы, 21а йортында; Олы Бисәр авылы, Заовраж урамы, 33 йортта; Ямбакты авылы, Октябрьгә

60 яшь урамы, 24а йортында урнашкан махсус мәгълүмат стендларында карар проектын, карар проекты буенча комиссия составын, карар проекты турында фикер алышуда гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен, карар проекты турында фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибен халыкка хәбәр итәргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) бастырып чыгарырга.

7. 2020 елның 15 апрелендә 14:00 сәгатьтә Льяш авыл мәдәният йорты бинасында карар проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

8. Карар проекты буенча комиссиягә Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының «Льяш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә халык алдында тыңлаулар турындагы Нигезләмә нигезендә карар проекты буенча фикер алышуны һәм кергән тәкъдимнәрне исәпкә алуны йөкләргә.

9. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Льяш авыл җирлеге башлыгы урынбасары И.А. Тихоновага йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Льяш авыл җирлеге**
**башлыгы** **И.А. Тихонова**

Татарстан Республикасы
Тәтеш муниципаль районы
Льяш авыл җирлеге Советының
2020 елның 12 мартындагы
54-1 номерлы карарына
1 нче кушымта

Проект

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Льяш авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

**«__» ________ 2020 ел** **№ __**

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы «Льяш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Фезераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законыны, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы «Льяш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 87 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Льяш авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Тәтеш муниципаль районы Льяш авыл җирлеге Советының 2013 елның 24 гыйнварындагы 27-3 номерлы карары нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы «Льяш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1. Җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә түбәндәгеләр керә:

1) җирлек бюджеты проектын төзү һәм карау, җирлек бюджетын раслау һәм үтәү, аның үтәлешен контрольдә тоту, җирлек бюджеты үтәлеше турындагы хисапны төзү һәм раслау;

2) җирлекнең җирле салымнарын һәм җыемнарын билгеләү, үзгәртү һәм юкка чыгару;

3) җирлекнең муниципаль милкендәге мөлкәтенә ия булу, аннан файдалану һәм эш итү;

4) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү;

5) җирлек халкын элемтә, җәмәгать туклануы, сәүдә һәм көнкүреш хезмәт күрсәтү белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;

6) җирлек халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял оештыру өчен шартлар тудыру;

7) Җирлек территориясендә физик культура, мәктәп спорты һәм массакүләм спорт үсеше өчен шартлар булдыру, җирлекнең рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру;

8) җирлекнең архив фондларын формалаштыру;

9) җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен контрольдә тоту, әлеге кагыйдәләргә туры китереп җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру;

10) адреслар бирү, адресларны үзгәртү, юкка чыгару, урам-юл челтәре элементларына (федераль әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, региональ яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, муниципаль районның җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан тыш) исемнәр бирү, җирлек чикләрендә планлаштыру структурасы элементлары атамаларын бирү, мондый атамаларны үзгәртү, юкка чыгару, дәүләт адреслы реестрында мәгълүмат урнаштыру;

11) авыл хуҗалыгы җитештерүчәнлеген үстерүгә ярдәм итү, кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өчен шартлар тудыру;

12) җирлектә балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру;

13) җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы гражданнарга һәм аларның берләшмәләренә ярдәм күрсәтү, халык дружиналары эшчәнлеге өчен шартлар тудыру;

14) каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым туплану) һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнашу;

15) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;

16) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру;

17) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;

18) милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга, җирлек территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен саклап калуга һәм үстерүгә, мигрантларны социаль һәм мәдәни адаптацияләүгә, милләтара (этникара) конфликтларны профилактикалауга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру;

19) җирлек халкының массакүләм ялы өчен шартлар тудыру һәм халык күпләп ял итә торган урыннарны төзекләндерүне оештыру, шул исәптән гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буе полосаларына ирекле үтеп керүен тәэмин итү;

20) Россия Федерациясе гражданнары законнары нигезендә үз белдеге белән төзелгән корылманы сүтү яки рөхсәт ителгән төзелеш параметрлары нигезендә тәртипкә китерү, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре белән билгеләнгән капиталь төзелеш объектларын территорияне планлаштыру документларына яисә федераль законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына мәҗбүри таләпләргә туры китерү турында карар кабул итү.»;

1.2. 28 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Авыл җирлеге Советының рәсми исеме - «Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Льяш авыл җирлеге Советы» муниципаль казна учреждениеесе.

Кыскартылган исеме - Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Льяш авыл җирлеге Советы.»;

1.3. 49 статьяның 1 өлешендәге 5 пунктының 9 абзацын төшереп калдырырга;

1.4. 49 статьяның 1 өлешендәге 6 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«- Россия Федерациясе гражданнары законнары нигезендә үз белдеге белән төзелгән корылманы сүтү яки рөхсәт ителгән төзелеш параметрлары нигезендә тәртипкә китерү, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре белән билгеләнгән капиталь төзелеш объектларын территорияне планлаштыру документларына яисә федераль законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына мәҗбүри таләпләргә туры китерү турында карар кабул итә;».

2. Тәтеш муниципаль районы Льяш авыл җирлеге Советының 2013 елның 24 гыйнварындагы 27-3 номерлы карары нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы «Льяш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының үзгәртелгән яңа редакциясен хупларга.

3. Әлеге карарны «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәве турында»гы 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ Федераль законда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алу өчен җибәрергә.

4. Әлеге карарны Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU.) бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Льяш авыл җирлеге**
**башлыгы** **И.А. Тихонова**

Татарстан Республикасы
Тәтеш муниципаль районы
Льяш авыл җирлеге Советының
2020 елның 12 мартындагы
54-1 номерлы карарына
2 нче кушымта

## Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы «Льяш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»гы Льяш авыл җирлеге Советы карары проекты буенча комиссия составы

| №п/п | ФИО | Вазифа |
|---|---|---|
| 1. | Тихонова Ирина Алексеевна | Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Льяш авыл җирлеге башлыгы, комиссия рәисе |
| 2. | Адайкина Зоя Игнатьевна | Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Льяш авыл җирлеге башкарма комитеты сәркатибе, комиссия сәркатибе |
| Комиссия әгъзалары: | | |
| 3. | Ахтонов Алексей Александрович | Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Льяш авыл җирлеге Советы депутаты |
| 4. | Курмышкина Ирина Николаевна | Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Льяш авыл җирлеге Советы депутаты |
| 5. | Альденейкина Светлана Петровна | Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Льяш авыл җирлеге Советы депутаты |

Татарстан Республикасы
Тәтеш муниципаль районы
Льяш авыл җирлеге Советының
2020 елның 12 мартындагы
54-1 номерлы карарына
3 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы «Льяш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»гы Льяш авыл җирлеге Советы карары проекты буенча фикер алышуда гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе**

Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы «Льяш авыл җирлеге «муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Льяш авыл җирлеге Советы карары проектына тәкъдимнәр Тәтеш муниципаль районы Льяш авыл җирлеге Советына Татарстан Республикасы, Тәтеш районы, Льяш авылы, Пролетар урамы, 22А йорты адресы буенча кушымта итеп бирелә торган үрнәк буенча төзәтмәләр таблицасы рәвешендә язма рәвештә кертелә:

| № п/п | Статья, өлеш, пункт, пунктча | Карар проекты тексты | Төзәтмә тексты | Төзәтмә тексты белән карар проекты тексты | Төзәтмә авторы (Ф.И.О., адресы, телефоны, эш (уку) урыны) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Тәкъдимнәр эш көннәрендә Льяш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында карар урнаштырылган көннән алып бер ай эчендә 8:00 сәгатьтән 16:00 сәгатькә кадәр кабул ителә.

2. Ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча тапшырыла: Татарстан Республикасы, Тәтеш районы, Льяш авылы, Пролетар урамы, 22А йорты («Устав турында фикер алышу» тамгасы белән).

Гаризалар эш көннәрендә 8:00 сәгатьтән 16:00 сәгатькә кадәр ачык тыңлаулар үткәрү датасына кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча кабул ителә.

3. Гражданнар тәкъдимнәре Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Льяш авыл җирлеге башлыгы тарафыннан теркәлә һәм Тәтеш муниципаль районы Льяш авыл җирлеге Советы утырышына тәкъдим ителә.

Татарстан Республикасы
Тәтеш муниципаль районы
Льяш авыл җирлеге Советының
2020 елның 12 мартындагы
54-1 номерлы карарына
4 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы «Льяш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»гы Льяш авыл җирлеге Советы карары проекты турында фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибе**

Үз тәкъдимнәрен дәлилләүче хокукыга ия булган гавами тыңлауларда катнашучылар булып, гавами тыңлаулар уздыру датасына кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча Тәтеш муниципаль районының Льяш авыл җирлеге Советына язма гаризалар биргән Тәтеш муниципаль районы Льяш авыл җирлегендә яшәүчеләр санала.

Гавами тыңлауларда чыгыш ясау хокукына ия булмаган Тәтеш муниципаль районы Льяш авыл җирлегенең барлык кызыксынган кешеләре дә катнаша ала.

Катнашучыларны теркәү гавами тыңлаулар башланырга 1 сәгать кала башлана.

Чыгыш ясау хокукына ия булган гавами тыңлауларда катнашучылар, гариза бирү вакытына карап, чират тәртибендә үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чакырыла.

Гавами тыңлауларда катнашучыларның чыгышлары 7 минуттан артык дәвам итәргә тиеш түгел. Рәислек итүче рөхсәте белән чыгыш ясау өчен вакыт озайтылырга мөмкин, ләкин 3 минуттан да артык түгел.

Гавами тыңлауларда катнашучылар чыгыш ясаганнан соң чыгыш ясаучыларга рәислек итүче рөхсәте белән сораулар бирергә хокуклы.

Гавами тыңлауларда катнашучылар тыңлаулар барышына чыгыш ясаучыга комачау итәргә хокуклы түгел.

Гавами тыңлауларда катнашучыларның барлык кисәтүләре һәм тәкъдимнәре секретариатка язма рәвештә тапшырыла һәм гавами тыңлаулар беркетмәсенә кушыла.